**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ПЕТРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**XXXXVI СЕССИЯ**

**КАРАР № 4**

Петровка авылы «20» май 2019 ел

**«Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Петровка авыл җирлеге» Башкарма комитеты турында» Нигезләмәне раслау хакында» Петровка авыл җирлеге Советының 2017 елның 3 июлендә булып узган XXIII сессиясендә кабул иткән 2нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән №131-ФЗ Федераль законга туры китерү максатларында һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Петровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

**Петровка авыл җирлеге Советы**

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Петровка авыл җирлеге Советының 2017 елның 3 июлендә булып узган XXIII сессиясендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Петровка авыл җирлеге» Башкарма комитеты турында»гы Нигезләмәне раслау хакында»гы 2нче карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 4 бүлектә:

*- 2 пунктның 5 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:*

«- Петровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен эшләр, хезмәтләр, товарлар сатып алуны гамәлгә ашырга»;»;

1.2. 5 бүлектә:

*- 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:*

«13) «Петровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннарга мөнәсәбәттә эшчәнлекне гамәлгә ашыру;».

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**«Петровка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **Р.Ф. Ибраһимов.**